ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**от 23 декабрь 2025 ел** **№ 35**

**Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану
өчен рөхсәт ителгән урыннарны
билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне тәэмин итү максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында”1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында” 2025 елның 22 декабрендәге 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Биеклеге 50 метрдан артык булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә, һава киңлегеннән файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасының оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.”

2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Апаз авылы, Совет урамы, 2 нче торак йорттан көньяк-көнчыгышка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

- Хәсәншәех авылы, парктан көньякка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

- Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, авыл клубының иске бинасыннан төньякка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

- Миркәм авылы, Профсоюз урамы, 20 нче торак йорттан төньяк-көнчыгышка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

- Каратай авылы, Х. Такташ урамы, 7 нче торак йорттан көнбатышка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

- Кзыл-Игенче авылы, Дальняя ур., 5 нче торак йорттан көнбатышка таба кимендә 300 метр чигенә торган ачык мәйданчык;

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Апаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Апаз авылы, Совет ур., 19 йорт; Хәсәншәех авылы, Космонавтлар ур., 20 йорт; Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты; Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Апаз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Котдусов